**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2023 елның 19 апреле 1339номер

# КАРАР

## Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Державино авыл җирлеге, Державино авылы, Җәббаров урамы, 47а йорт адресы буенча урнашкан кадастр номеры: 16:24:060101:273 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын раслау турында.

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставына таянып, территорияләрне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, 2023 елның 18 мартындагы гавами тыңлаулар нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Державино авыл җирлеге, Державино авылы, Җәббаров урамы, 47а йорт адресы буенча урнашкан кадастр номеры: 16:24:060101:273 булган җир кишәрлеге территориясен ызанлау проектын расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында-http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А.П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын**
**башкаручы** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**